# ТЕЛ ХОКУКЛАРЫ БУЕНЧА МАНИФЕСТ

*Халыкара ПЕН-үзәге бөтендөнья язучыларын берләштерә. Унбиш ел элек Барселонада Халыкара ПЕН-үзәгенең тәрҗемә эшләре һәм лингвистик хокуклар Комитеты беренче тапкыр Лингвистик хокуклар буенча Гомуми декларация дөньяга игълан итте. Бүген шул ук Комитет, Жиронада (Испания) җыелып, Гомуми декларация Манифестының төп ун принцибын белдерде.*

1. Лингвистик төрлелек дөнья мирасы булып тора, ул бәяләнергә һәм сакланырга тиеш.

2. Барлык телләргә һәм мәдәниятләргә ихтирам – бөтен дөньяда диалог һәм тынычлык төзү һәм аны саклау процессының нигезе булып тора.

3. Барлык кешеләр сөйләшергә үз җәмгыятенең үзәгендә өйрәнәләр, бу аларга яшәргә, тел һәм мәдәният белән кулланырга, үзенчәлекле булырга мөмкинлек бирә.

4. Төрле телләр һәм төрле аралашу юллары элемтә чарасы гына түгел, алар шәхес үсеше һәм мәдәниятне дөньяга китерүче мөхит булып тора.

5. Һәрбер тел бергәлеге үз территориясендә үз телен официаль тел буларак кулланырга хокуклы.

6. Мәктәптә белем алу территориядәге тел бергәлегенең аралашу теле буларак дәрәҗәсен үстерергә тиеш.

7. Һәр кеше өчен дә төрле телләр турында гомуми белемгә ия булу кирәк, чөнки бу берберенә карата мәрхәмәтлелек һәм интеллектуаль ачыклыкка этәрә, үзеңнең телеңне яхшырак белергә ярдәм итә.

8. Тәрҗемә эше, бигрәк тә төрле мәдәниятләрнең бөек әсәрләрен тәрҗемә итү, кешеләр арасындагы бер-берсен аңлау һәм хөрмәт итүнең бик әһәмиятле бер өлешен тәшкил итә.

9. Массакүләм информация чаралары – лингвистик төрлелек концепциясенең дәрәҗәсен дөрес һәм өзлексез күтәрү максатында лингвистик төрлелекне популярлаштыруның әһәмиятле чарасы.

10. Үз телеңне куллану һәм саклау хокукы Берләшкән Милләтләр Оешмасы тарафыннан кешенең төп хокукларының берсе булып танылырга тиеш.

Translated by Yagfar Garipov